| «Каралды» | «Килешенде» | «Расланды» |
|---|---|---|
| МБ җитәкчесе | Укыту эшләре буенча | Мәктәп директоры |
| ______Копылова Г.Г. | директор урынбасары | ______Ахметова Г.З. |
| Беркетмә №1 | ______Магсумова Г.Ф. | Приказ № |
| « 27 » 08.2023 нче ел | «31 » 08. 2023 нче ел | «31 » 08. 2023 нче ел |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**
**“Кәче төп гомуми белем мәктәбе”**
**муниципаль бюджет гомуми учреждениесенең**
**беренче квалификацион категорияле туган тел һәм әдәбият укытучысы**
**Әхмәтҗанова Энҗе Госман**
**кызының**

**«Сәхнә серләре»**
# ТҮГӘРӘГЕНЕҢ ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Педагогик киңәшмә
утырышында каралды
Беркетмә №1
31 нче август 2023 нче ел

2023-2024 нче уку елы

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

**Театр –** халыкнын үзаңы үсеше нәтиҗәсендә барлыкка килгән сәнгать төре. Сәхнәдә уйнау, тамашачыга күрсәтү өчен коллектив тарафыннан иҗат ителгән сәнгатьнең бер төре театр сәнгате дип йөртелә.

Татар театр сәнгатенең бай тарихы, матур традицияләре бар. Ул күп тармаклы зур дәрьяны хәтерләтә. Дәрья башы бик борынгы заманнарга барып тоташа. Милли театрның беренче яралгылары халык уеннарында, җыен һәм сабантуй кебек бәйрәмнәрдә, туй йолаларында күренә. Заманалар үтү белән, билгеле бер тарихи шартларга бәйле рәвештә, профессиональ татар театры мәйданга килә. Бу 1905 нче елгы беренче рус революциясе нәтиҗәсендә тормышка аша. «Сәяр», «Нур», «Ширкәт» һ.б. профессиональ труппалар оеша. Төрле шәһәрләрдә җирле хәвәскәрлек хәрәкәте көчәя. Татар театры Петербург, Мәскәү, Идел буе, Урта Азия, Урал һ.б. төбәкләргә җәелеп, тармакланып үсеп китә.

«Милли театр ул, академия, университет, музейлар шикелле үк, милләтнең өлгереп җитуен билгели»,- дип бәяли бөек рус язучысы А.Н.Островский. Татар театр сәнгате Россиядә яшәгән төрки халыклар арасында беренчеләрдән булып, балигълык дәрәҗәсен яулый. Ул үзенчәлекле үсеш баскычлары үтеп, октябрь революциясен милли сәхнә сәнгатенә ныклы нигез салынган хәлдә каршылый.

Татар сәхнәсенен Октябрьгә кадәргесе киң массага ан-белем, мәгърифәт таратуга, тамашачыны мәдәниятле, тәрбияле итүгә юнәлтелгән була. Театр сәнгатенен бу өлкәдәге беренче карлыгачлар «Бичара кыз» (Г.Ильяси), «Рәдде бичара кыз» (Ф.Халиди) пьесалары белән башлануы, 1906 елга кадәр театрнын бары хәвәскәрлек чоры гына кичерүе билгеле. Беренче ачык спектакль 1906 елда Казанда курсәтелеп, матбугат битләрендә театрга караган мәкаләләр, фикерләр күренә. Театрнын тамашачысы арта. Татар театры башта бер урында гына оешып эшләми. Казанда «Сәяр» (ил гизуче) труппасы оеша. Труппанын житәкчеләре, андагы беренче актерлар, режиссерлар шул вакыттагы матбугат язмалары аша безгә мәгълум. Татар театрынын үткән юлы гаять катлаулы һәм бай тарихлы ул. Театр сәнгате халыкнын гасырлар буена бөртекләп жыела килгән акыл һәм рухи байлыгын, мирасын чагылдыручы олы хәзинә дә.

Билгеле, программада татар театры тарихын бөтен тулылыгы белән чагылдыру мөмкин түгел һәм ул аны үзмаксат итеп куймый да. Шулай да кереш дәресләрдә югарыда күрсәтелгән белешмәләр укучы күңелендә урын алырга тиеш. Болар белән беррәттән, укучы театрның режиссерлары, язучы (драматург), артистлар турында да тирән мәгълүматлы булырга тиеш. Шулай ук драма жанрлары (трагедия, комедия, драма), аларнын тагы да ваграк өлешләрен дә танып белу әһәмиятле. Театр сәнгатендә әсәрне сәхнәгә куярга әзерләүче кешенең режиссер булуы турында белешмә бирү кирәк. Программа драматургларның иҗатын бөтен тулылыгы белән өйрәнүне дә үз эченә алмый. Ләкин татарның классик драматургларың һәм аларнын әсәрләре халкыбызнын йөзек кашы, җәүһәрләре, милли хәзинәләребез булуына төшендеру дә унышлы булыр.

Жыеп кына әйткәндә, программанын бурычы - театр сәнгатенен башка сәнгать төрләреннән аермалы төп үзенчәлекләрен аңлату; татар театр сәнгатен бала күңеленә якынайту, аңарда милли хисләр тәрбияләү; театарның бай хәм катлаулы тарихы белән кызыксындыру, бигрәк тә театрнын башлангыч этабы белән таныштыру, анын беренче адымнары турында мәгълумат бирүне күздә тота. Балалар өчен язылган әсәрләрне сәхнәләштерергә өйрәтү, образларны иҗат итү серләренә төшендерү, сәнгатьле сәйләм кунекмәләрен формалаштыру, гомумән, укучыларның ижади сәләтләрен устерү, театр сәнгатенә мәхәббәт уяту һәм милли узаң формалаштыру кебек алымнар программаның төп асылын тәшкил итә. Программаны төзегәндә Хәнуз Мәхмутовнын «Октябрьга кадәрге татар театры» (1988), «Татар совет театры» (1975), Ибраһим Нуруллинның «Драматургиядә жанр формалары» («Соембикә», 1996, №12) дигән хезмәтләре һ.б. матбугат материаллары файдаланылды. Программа, нигездә, 7-8 нче сыйныф укучылары белән һәм бер ел вакыт әчендә әшләүне куз алдында тотып төзелде.

## Түгәрәкнең максаты һәм бурычлары

**1. Белем бирү, өйрәтү максаты :**

1. Укучыларны татар театр сәнгатен аңларга һәм образларны иҗат итәргә өйрәтү.

**Бурычлары :**

1. Театр сәнгатенең мәгънәсен аңлауларына ирешү.
2. Образларны тормышчан иҗат итү серләренә төшендерү.

**2. Тәрбияви максат :**

1. Татар театры тарихы, анын беренче карлыгачлары, беренчел алымнары белән кызыксыну хисләре уяту.
2. Татар театры сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү, әхлак сыйфатлары формалаштыру, киләчәк тормышка әзерләү.

**Бурычы :**

1. Театрнын үткән юлын, анын беренче яралгыларын аңлауларына ирешү.
2. Драма жанрының төрләрен аера алуларын булдыру.
3. Классик әсәрләр сәхнәләштерү.

**3. Үстерелешле максат :**

1. Сәнгатьле уку һәм сөйләм күнекмәләрен үстерү.

2. Ижади сәләтләрен үстерү һәм тирәнәйтү.

**Бурычы :**

1. Аеруча балалар өчен язылган һәм классик әсәрләр сәхнәләштерү, иҗат итү.
2. Төрле бәйге-ярышларда, ата-аналар алдында чыгышлар ясау.
3. Сүз сәнгатеннән алган белемнәрен тагы да тирәнәйтү, гомумиләштерү.

Түгәрәк дәресләре төрле формада үткәрелә. Күбрәк теоретик һәм практик юнәлештә эш башкарыла. Дәрес-әңгәмә, дәрес-очрашу, дәрес-экскурсияләр үткәрү дә күздә тотыла.Т өп игътибар балаларның ижади сәләтен үстерүгә, аларны милли җанлы, милли рухлы итеп тәрбияләүгә, сәнгатьле һәм образлы сөйләм формалаштыруга, мөстәкыйль шәхес үстерүгә, әзерләүгә юнәлтелә.

**Уку елы ахырында укучылар белергә тиеш :**

1. Театр сәнгате, анын төп үзенчәлеге.
2. Татар театр сәнгате, анын тәүге адымнары, формалашу чоры, үткән юлы.
3. Милли театрыбыз, аның беренче карлыгачлары (Язучы-драматурглары, артист-актерлары, режиссерлары).
4. Драма жанрлары.
5. Классик драма әсәрләре, классик драматурглар ижаты.
6. Актерлык бурычы, образга керү һәм тоемлап сөйләү.
7. Режиссер күрсәтмәләрен анлый, үти белү.
8. Мәдәниятне аңлый белүче, ижади талантлы, әхлак сыйфатларына ия кеше булу.

**Укучы эшли, башкара белергә тиеш :**

1. Театр сәнгатен башка сәнгать төрләреннән аера.
2. Татар театры тарихы, үткән юлы белән таныш.
3. Сәнгатьле сөйли, образга керә.
4. Актерлык талантына ия.
5. Ижади һәм мөстәкыйль, үз киңәшләрен башкаларга да бирә ала.
6. Драма төрләрен аера, классик әсәрләрне анлый.
7. Сәхнә тормышы белән таныш, башка милләт театрлары белән дә кызыксына.

**Тематик план**

| № | Тема, эш торләре | Барлык | Теория | Практика |
|---|---|---|---|---|

| | | сәгать саны | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш<br>1) оештыру<br>2) максат, бурычлар, эш планы | 2 сәг. | 2 сәг. | |
| 2 | Театр сәнгате, анын төп үзенчәлеге | 2 сәг. | 2 сәг. | |
| 3 | Татар театры тарихы, анын беренче адымнары, үткән юлы | 16 сәг. | 14 сәг. | 2 сәг. |
| 4 | Татар театрынын бүгенгесе | 4 сәг. | 2 сәг. | 2 сәг. |
| 5 | Драма жанры төрләре | 8 сәг. | 6 сәг. | 2 сәг. |
| 6 | Әсәрне иҗат итәргә әзерләү, актерлык серләрен өйрәнү | 48 сәг. | 48 сәг. | |
| 7 | Әсәрне сәхнәгә кую (актерлык талантын тикшеру, ныгыту) | 32 сәг. | | 32 сәг. |
| 8 | Экскурсия, очрашулар | 10 сәг. | | 10 сәг. |
| 9 | Театр бәйгеләренә әзерләнү | 16 сәг. | | 16 сәг. |
| 10 | Йомгаклау дәресе | 6 сәг.<br>**144 сәг** | 3 сәг.<br>**77 сәг.** | 3 сәг.<br>**67 сәг.** |

**Программа эчтәлеге**

| № | ДӘРЕС ТЕМАСЫ | Барл | Тео- | Прак |
|---|---|---|---|---|

| | | | сәг. | рия | тика |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес (2сәг) | | | | |
| 2 | Театр сәнгате, анын төп үзенчәлеге (2 сәг) | | | | |
| 3 | Татар театры тарихы, беренче адымнары, үткән юлы (16 сәг)<br>1) Театрнын үсеш баскычлары, формалашу чоры<br>2) Беренче драматурглар, аларнын әсәрләре | «Бичара кыз» әсәрен уку | | | |
| | 3) Театрнын беренче карлыгачлары | Габдулла Кариев, С.Волжеская һ.б. турында истәлекләр уку, | | | |
| | 4) Беренче труппалар, ачык театр көне турында белешмә бирү | өзекләр,рәсемнәр карау | | | |
| | 5) Татар театры йолдызлары, драматурглары белән танышу:<br>М.Фәйзи,К.Тинчурин<br>Ф.Бурнаш<br>Т.Гыйззәт<br>Н.Исәнбәт һ.б. | Г.Камал турында истәлекләр уку, әсәрләреннән өзекләр карау | | | |
| | Бугенге татар театр сәнгате (4 сәг) | Совет чорында ижат иткән артистлар, драматурглар эшчәнлеген тикшеру, өйрәну, әсәрләрдән өзекләр карау, уку. | | | |
| | Бүгенге драматурглар, аларнын ижат алымнары | | | | |
| | 1) Г.Камал театры коллективы эшчәнлеге | Анның татар культурасындагы роле (өзек тынлау- М.Сәлимжанов) | | | |
| | 2) К.Тинчурин исемендәге театр артистлары, аларнын ижаты, театр | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | сәнгатендә тоткан урыннары.<br><br>Драма жанры торләре:<br>1) Трагедия жанры<br>2) Комедия жанры<br>3) Драма жанры<br>4) Башка жанр торләре:<br>- водевил<br>- мелодрама х.б.<br><br>5) Конфликт турында төшенчә<br><br>Сәхнә әсәрләрен иҗат иту, актерлык серләренә өйрәнү, өйрәтү дәресләре<br>1) Г.Камалнын «Беренче театр» әсәреннән өзекләр<br><br>2) Кечкенә күләмле әсәрләр (скетч, мәзәкләр) иҗат итү<br><br>3) Әкиятләр сәхнәләштерү<br><br>4)Туфан Миннуллин әсәрләренә күзәтү ясау<br>5)Батулла, Юныс Сафиуллин, Зөлфәт Хәким әсәрләре буенча сәнгатьле уку дәресләре<br>6) Хужа Насретдин мәзәкләре<br><br>7) Ш.Галиев, Р.Миннуллин әсәрләрен уку<br><br>Әсәрләрне сәхнәгә кую. «Пионер сәхнәсе» жыентыгы буенча, классик әсәрләр буенча | Әсәрләрдән озекләр карау<br><br>Театр артистлары, рәсемнәре, видеоязмалар карау, актерлык серләренә өйрәну<br><br>Видеоязмалар карау: Г.Исхакый «Золәйха» Г.Камал «Банкрот» М.Фәйзи «Галиябану» Т.Гыйззәт «Бишбүләк» әсәрләреннән өзекләр тынлау, аерым урыннарын сәхнәләштерү Диалоглар уку, образлы сөйләм<br><br>Өзекне сәхнәгә кую<br><br>«Белмим», «Мәктәп юлы» әсәрләрен сәхнәләштерү, башлангыч сыйныфлар өчен | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Экскурсия һәм очрашулар<br>1) Авыл мәдәният йортында куела торган спектакль, концертларга экскурсия<br>2) К.Тинчурин теары артистлары белән очрашу<br>«Мәктәп театрына киң юл» бәйгесе<br>1) Әсәр сайлау(Ф.Кәрим ”Шакир Шигаев”драмасы) | Аерым образларнын чыгышы, образга керүне курсәтү<br>Әкиятләргә сценарийлар язу<br>Әдәби-драматик тапшырулар тынлау (кумәк)<br>Өзекләр уку, сәнгатьле уку, сөйләү<br>Аерым әсәрләрдән өзекләр, күренешләр сәхнәләштерү, карап өйрәнү яки тынлау<br>Аерым мәзәкләрне сәхнәгә кую<br>Шаян шигъри әсәрләрне сәхнәләштерү («Пәрәмәч», «Камырша»<br>1) «Дуслар» әсәреннән өзекләр кую<br>2) Г.Камалнын «Банкрот» әсәреннән өзекләр уку, сәхнәләштерү<br>3) Артист Наил Шәйхетдинов ижатын видеоязмадан | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2) Образлар бүлү<br>3) Иҗат иту<br>4) Костюм нар әзерләү<br>5) Сәхнә бизәлеше<br>Йомгаклау<br><br><br>«Безнен уньшларыбыз» | карау<br>4) «Мунча ташы» буенча озекләр карау, тынлау<br>5) Г.Нәбиуллиннын «Тын елга буенда» яки Г.Бакировнын «Безнен матуркайлар» әсәреннән өзекләр өйрәнү, сәхнәгә кую<br>6) К.Тинчурин, Н.Исәнбәт әсәрләрен уку, өзекләрен сәхнәгә кую<br>Культпоход (мәдәният йортына)<br><br>Очрашу-кичә<br><br><br><br>Сәламәтлек темасы буенча әсәр сайлау, иҗат иту, актерлык сәләтен күрсәтү<br><br><br>Иҗат отчеты (аерым әсәр иҗат итү)<br>Мәкалә язу | | | |

**Пограмманы тормышка ашыру**

Тугәрәк дәресләре өчен бүлмә : Татар теле һәм әдәбияты кабинеты

Жиһазлау : телевизор, видео һәм аудиомагнитофоннар.

Курсәтмәлелек : Театр тормышыннан куренешләр; артистлар, режиссерлар, драматурглар турында рәсемле истәлекләр; сәхнә йолдызлары, Г.Камал, К..Тинчурин театрлары турында белешмә китаплар.

**Әдәбият исемлеге**

**1. Укытучы очен :**

1) Хәнуз Мәхмутов, Илтани Илялова, Бәян Гыйззәт. Октябрьга кадәрге татар театры. – Казан, 1988.
2) Б.Гыйззәт, Х.Мәхмутов, А.Әхмәдуллин, И.Илялова. Татар совет театры. – Казан, 1975.
3) А.Әхмәдуллин. Сәхнә һәм тормыш. – Казан, 1976.
4) Р.Жиһаншина. Күңелем түреннән.
5) Төрле журналлар, альбомнар, белешмәләр, рәсем-фотолар, артист язмалары.
6) Әдәбият дәреслекләре.
7) Сәхнә әсәрләре : Г.Камал, К.Тинчурин һ.б.

**2. Укучылар очен әдәбият:**

1) Мәктәп сәхнәсе. 1-2 кисәк.
2) Пионер сәхнәсе. 6-8 кисәк
3) Ш.Галиев.Күнелле сәхнә.-Казан, 1971.
4) Ш.Мостафин. Безнең сәхнә. –Казан, 1989.
5) Мәзәкләр жыентыгы.
6) Классик драматурглар ижаты үрнәкләре.
7) И.Нуруллин. Драматургиядә жанр формалары.

**Календарь тематик план**

| № | ТЕМА, ӘЧТӘЛЕК | СӘГ. | ҮТКӘРУ | ДӘРЕ |
|---|---|---|---|---|

| | | САНЫ | ВАКЫТЫ (АЕ) | С төре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес. | 2 | | Теор. |
| | Театр сәнгате, аның халык мәдәниятен үстерүдәге роле | 2 | | Теор. |
| | Театрның  барлыкка килү, формалашу чоры | 2 | | Теор. |
| | Беренче дрматурглар иҗаты | 2 | | Теор. |
| | Театрның беренче карлыгачлары | 2 | | Теор. |
| | Татар театры. Ачык рәвештә куелу тарихы | 2 | | Теор. |
| | «Сәйяр» труппасы, анын иҗаты, беренче йолдызлары | 2 | | Теор. |
| | Татар Дәүләт театры, аның  беренче ижат труппасы (артистлар, классик драматурглар) | 2 | | Теор. |
| | Бугенге драматурглар, аларның ижат алымнары (кыскача белешмә) | 2 | | Теор. |
| | Г.Камал һәм К.Тинчурин театры эшчәнлеге | 2 | | Теор.<br>Практ. |
| | Драма жанрлары | | | |
| | 1) трагедия | 2 | | Теор. |
| | 2) комедия | 2 | | Практ. |
| | 3) драма | 2 | | Практ. |
| | 4) водевиль, мелодрама | 2 | | Теор. |
| | Конфликт | 2 | | Теор. |
| | Ремарка һ.б. төшенчәләр, мәзәкләр уку | 2 | | Теор.<br>Практ. |
| | Г.Камал иҗаты | 2 | | Теор. |
| | Г.Камалнын «Беренче театр» әсәреннән өзекләр сәхнәләштерү | 2 | | Теор. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | «Беренче театр» әсәреннән өзекләр сәхнәләштерү | 2 | | Теор. |
| | «Беренче театр» әсәреннән өзекне сәхнәләштерү | 2 | | Теор. |
| | Әсәрне сәхнәгә кую | 2 | | Практ. |
| | Скетчлар өйрәнү : | 2 | | Теор. |
| | Р.Шәрәфинен «Белмим» әсәрен сәхнәгә кую | 2 | | Практ. |
| | «Мәктәп юлы» әсәреннән өзек өйрәнү | 2 | | Теор. |
| | Скетчларны сәхнәгә кую | 2 | | Практ. |
| | М.Хәсәнов ижаты. «Галим һәм Сәлим» әсәрен уку, фикер алышу | 2 | | Теор. |
| | «Галим һәм Сәлим» әсәрен рольләргә булу, образларга керу, актерлык серләре белән танышу. | 2 | | Теор. |
| | «Галим һәм Сәлим» әсәреннән өзекләрне сәхнәгә кую | 2 | | Практ. |
| | Әкиятләр сәхнәләштерү, әкият кичәсенә әзерлек:<br>1) әкиятләр сайлау | 2 | | Практ. |
| | Әкиятләргә сценарий язу, сәхнәгә куярга әзерләү | 2 | | Теор. |
| | Әдәби-драматик тапшырулар тыңлау | 2 | | Практ. |
| | Бүгенге драматурглар һәм Т.Миңнуллин әсәрләренә күзәтү ясау, ижатын өйрәнү | 2 | | Теор. |
| | Т.Миннуллиннын «Иптәш командир» әсәрен уку. | 2 | | Практ. |
| | Батулла ижаты. «Сипкелле малай» әсәрен сәнгатьле уку | 2 | | Практ. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Юныс Сафиуллин ижатына күзәтү ясау<br>Зөлфәт Хәким әсәрләреннән өзекләр карау, тынлау | 2<br>2 | | Теор.<br>Практ. |
| | З.Хәким әсәрләреннән өзекләрне сәхнәләштерү | 2 | | Практ. |
| | Х.Насретдин мәзәкләрен уку, сәхнәгә куярга әзерлек | 2 | | Теор. |
| | Мәзәкләрне сәхнәгә куярга әзерлек, сәхнәләштеру, | 2 | | Теор. |
| | Шаян шигъри әсәрләр уку хәм тынлау, сәхнәләштеру, сәнгатьле уку | 2 | | Практ. |
| | **Әсәрләрне сәхнәгә кую – 32 сәг.** | | | |
| | «Бәйрәм табыны» әсәрен сәхнәләштеру | 2 | | Теор. |
| | Өзек сайлау, образлар сайлап, актерлык таләпләренә өйрәтү | 2 | | Теор. |
| | Әсәрне өлешләп уку, нәниләр өчен кую | 2 | | Практ. |
| | Әсәрдән өзекләрне сәхнәгә кую | 2 | | Практ. |
| | Г.Камалнын «Банкрот» әсәрен видеоязмадан карау (Хәрәкәтләр алымы) | 2 | | Теор. |
| | «Банкрот» әсәренен 2 нче пәрдәсе буенча өзек сәхнәләштерү яки образларга керү техникасы | 2 | | Практ. |
| | К.Тинчуринчылар ижаты. Артист Наил Шәйхетдинов яки Алмаз Фатхуллин иҗатыннан аерым эпизодлар карау | 2 | | Теор.<br>Практ. |
| | «Мунча ташы» язмалары буенча өзек карау һәм тыңлау | 2 | | Практ. |
| | Г.Нәбиуллин ижаты. «Тын елга буенда» әсәреннән өзекләр уку, өйрәнү:<br>1) образлар сайлау | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2) әсәрдән өзекләр өйрәнү | 2 | | Теор. |
| | 3) әсәрне сәхнәгә куярга әзерләү | 2 | | Теор. |
| | 4) әсәрнен ремаркалары буенча | 2 | | Теор. |
| | хәрәкәт иту | 2 | | Теор. |
| | 5) әсәрдәге конфликтларны дөрес | | | |
| | сурәтләү юлларын өйрәнү | 2 | | Теор. |
| | 6) әсәрне сәхнәләштерү алымнары | | | |
| | (төрле әсәрләре буенча) | 2 | | Теор. |
| | 7) әсәрне сәхнәгә кую дәресләре | | | |
| | (төрле әсәрләрдән) | 2 | | Практ. |
| | | 2 | | Практ. |
| | К.Тинчурин ижатына күзәтү ясау. | | | |
| | «Зәңгәр шәл» дән күренешләр карау | 2 | | Теор. |
| | | | | Практ. |
| | К.Тинчурин «Американ». Әсәрдән | | | |
| | озекләр уку, сәхнәгә куярга әзерләну | 2 | | Теор. |
| | | | | Практ. |
| | Н.Исәнбәтнен «Аулак ой» әсәреннән | | | |
| | озекләр уку, аерым урыннарында образга | 2 | | Теор. |
| | кереп карау. | | | Практ. |
| | Әкскурсия, очрашулар (кайсы вакытта | | | |
| | оештырылуына карый): (10сәг) | | | |
| | 1) мәдәният йортында куела торган | | | |
| | спектакль, театр, концертларда | 2 | | Практ. |
| | катнашу, аларны бергәләп карау, | 2 | | |
| | әнгәмә дәресләр | 2 | | |
| | 2) К.Тинчурин театры артистлары | | | |
| | белән танышу | 4 | | Практ. |
| | Мәктәп театрына киң юл» бәйгесенә | | | |
| | әзерләнү | | | |
| | 1) әсәр сайлау, аның темага туры | 16 | | |
| | килүе | | | Практ. |
| | 2) сәхнә бизәлеше, костюмнар | | | |
| | әзерләү | | | Практ. |
| | 3) иҗат итү | | | |
| | **Йомгаклау дәресләре** | | | |
| | Мәктәп укучылары, әти-әниләр алдында | | | |
| | ачык спектакль кую (өйрәнгән әсәрләр | 2 | | Практ. |
| | арасыннан) | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Ижат эше, уңышлар турында мәкалә язу<br>Зачет дәрес<br>Театр сәнгате, театр тарихы һәм аның тормыштагы әһәмияте | <br>2<br>2<br>2 | | <br>Практ.<br>Теор.<br>Теор. |

**ТӘРБИЯ ЭШЕ ПЛАНЫ**

**Максат :** укучыларны татар театр тарихы, анын үткәне һәм бүгенге иҗаты белән кызыксындыру, театр сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү, аларда әхлак сыйфатлары формалаштыру

**Бурычы:**
Татар театры белән кызыксындыру, милли хисләр уяту
Киләчәк тормыш өчен милли рухлы шәхес үстерү
Сәхнә тормышына лаеклы алмаш әзерләү

| № | Үткәреләчәк чаралар | Үткәру вакыты | Үткәру урыны |
|---|---|---|---|
| 1<br><br><br>2 | Ата-аналар белән эш:<br>А) ата-аналар җыелышы<br>Б) аерым әңгәмәләр<br>Чаралар:<br>- «Көзге бал»<br>- Театр көне<br>- Чыршы бәйрәме<br>- Театр бәйгесе<br>- 23 февраль<br>- 8 март<br>- Юмор кичәсе<br>- Балалар өчен сәнгать фестивале | <br>Чирек саен<br>Даими<br><br>Октябрь<br>Ноябрь<br>Декабрь<br>Январь<br>Февраль<br>Март<br>Апрель<br>Апрель-май | <br>Класс,<br>мәктәп<br><br>Мәктәп<br>Мәктәп<br>Мәд. йорты<br>Мәд.йорты<br>Мәктәп<br>Мәктәп<br>Мәктәп<br>Мәд.йорты |

Прошнуровано, пронумеровано и скреплено печатью ______листов

Подпись ________ Г.З.Ахметова